КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июль г.Казань № 645

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 апрель, 285 нче; 2014 ел, 11 октябрь, 753 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1084 нче; 2015 ел, 31 декабрь, 1037 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1049 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1094 нче; 2018 ел, 13 июль, 570 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1245 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 743 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1219 нчы; 2020 ел, 29 декабрь, 1224 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1330 нчы; 2022 ел, 19 апрель, 367 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү (алга таба – Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән нәтиҗәле идарә итү |
| Программаның бурычлары | Бюджет системасының озак вакытлы баланслылыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү<br>дәүләт бурычы белән нәтиҗәле идарә итү<br>җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2014 – 2025 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | 2014 – 2025 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме – 172 431 209,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 172 409 361,7 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән 21 848,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча: |

| Ел | Финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән | федераль бюджет акчасы исәбеннән |
| 2014 | 10 667 262,8 | 10 667 262,8 | - |
| 2015 | 8 964 802,1 | 8 964 802,1 | - |
| 2016 | 10 551 579,9 | 10 551 579,9 | - |
| 2017 | 11 186 510,1 | 11 186 510,1 | - |
| 2018 | 13 547 784,5 | 13 547 784,5 | - |
| 2019 | 14 678 350,9 | 14 678 350,9 | - |
| 2020 | 11 230 770,7 | 11 230 770,7 | - |
| 2021 | 16 368 038,2 | 16 346 190,2 | 21 848,0 |
| 2022 | 21 701 446,6 | 21 701 446,6 | - |
| 2023 | 18 926 053,2 | 18 926 053,2 | - |
| 2024 | 16 984 582,6 | 16 984 582,6 | - |
| 2025 | 17 624 028,1 | 17 624 028,1 | - |
| Барлыгы | 172 431 209,7 | 172 409 361,7 | 21 848,0 |

| | |
|---|---|
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Программаны тормышка ашыру срогы ахырына түбәндәгеләр планлаштырыла:<br>Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә карата (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгының бюджет керемнәреннән (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) һәм бюджет чыгымнарыннан (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны исәпкә алмыйча) чыгып исәпләнгән мөнәсәбәтенең мәгънәсен 8 проценттан артмаган дәрәҗәдә тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә (субвенцияләрне исәпкә алмыйча) программалар кысаларында төзелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының чагыштырма күләмен кимендә 83,5 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган чыгымнарны исәпкә алмыйча) капиталь характердагы Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының өлешен кимендә 9 процент дәрәҗәсендә (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр хисабына гамәлгә ашырыла торган капиталь характердагы чыгымнарны исәпкә алмыйча) тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең үткән ел дәрәҗәсенә карата кимендә 103,2 процент күләмдә үсеш темпына ирешергә;<br>Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләмен 270,6 млрд.сум тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләмен 328,1 млрд.сум күләмдә тәэмин итәргә;<br>хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләме арасындагы мөнәсәбәтләрнең хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә нисбәтен (кире кайтарылмый торган кермнәр күләмнәрен исәпкә алмыйча) 33,6 проценттан артмаган дәрәҗәдә тәэмин итәргә; |

| | |
|---|---|
| | чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда җирле бюджетлар чыганакларының һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларның җирле әһәмият-тәге мәсьәләләрне хәл итүгә киткән чыгымнарның тиешле күләменә кимендә 100 процент дәрәҗәсендә булуын тәэмин итәргә»; |

Программаның 2 бүлегендә:

егерме бишенче абзацта «кимендә 84,5 процент» сүзләрен «кимендә 83,5 процент» сүзләренә алмаштырырга;

егерме җиденче абзацта «кимендә 103,6 процент» сүзләрен «кимендә 103,2 процент» сүзләренә алмаштырырга;

егерме сигезенче абзацта «кимендә 262,2 млрд.сум» сүзләрен «кимендә 270,6 млрд.сум» сүзләренә алмаштырырга;

егерме тугызынчы абзацта «кимендә 318,0 млрд.сум» сүзләрен «кимендә 328,1 млрд.сум» сүзләренә алмаштырырга;

утызынчы абзацта «36,7 проценттан артмаган» сүзләрен «33,6 проценттан артмаган» сүзләренә алмаштырырга;

утыз икенче абзацта «2014 – 2024 еллар» сүзләрен «2014 – 2025 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2014 – 2025 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме – 172 431 209,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 172 409 361,7 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән 21 848,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

| Ел | Финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | Барысы | шул исәптән | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән | федераль бюджет акчасы исәбеннән |
| 2014 | 10 667 262,8 | 10 667 262,8 | - |
| 2015 | 8 964 802,1 | 8 964 802,1 | - |
| 2016 | 10 551 579,9 | 10 551 579,9 | - |
| 2017 | 11 186 510,1 | 11 186 510,1 | - |
| 2018 | 13 547 784,5 | 13 547 784,5 | - |
| 2019 | 14 678 350,9 | 14 678 350,9 | - |
| 2020 | 11 230 770,7 | 11 230 770,7 | - |
| 2021 | 16 368 038,2 | 16 346 190,2 | 21 848,0 |
| 2022 | 21 701 446,6 | 21 701 446,6 | - |
| 2023 | 18 926 053,2 | 18 926 053,2 | - |
| 2024 | 16 984 582,6 | 16 984 582,6 | - |
| 2025 | 17 624 028,1 | 17 624 028,1 | - |
| Барлыгы | 172 431 209,7 | 172 409 361,7 | 21 848,0 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

Программаның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаның башисемендә һәм исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин